ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 һәм 7 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 29 мартында
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» 2005 елның 18 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 4, № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:
«дәүләт ярдәме чаралары күрсәткәндә барлыкка килгән документлар – дәүләт ярдәме чарасы буларак бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан файдаланганда һәм аларны бирү процессында барлыкка килгән документлар. Документлар исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.»;

2) 7 статьяның өченче өлешендә «һәм проектлау документларының» сүзләрен «, проектлау документларының һәм дәүләт ярдәме чаралары күрсәткәндә барлыкка килгән документларның» сүзләренә алмаштырырга.

## 2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 12 апрель
№ 19-ТРЗ